# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге составына керүче Иске Завод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 8 «16» ноябрь, 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Иске Завод торак пунктында 2021 елның «16» ноябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Иске Завод торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- вак таш җәеп, юлларны ремонтлау:
(сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
Иске Завод торак пунктында, Ленин урамы,Совет урамы;
- Иске Завод торак пунктында урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру яки алыштыру;
- Иске Завод торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 51 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 34 кеше,66% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 34 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Иске Завод торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлегенең Иске Завод торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Иске Завод торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- вак таш җәеп, юлларны ремонтлау:
(сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)
Иске Завод торак пунктында, Ленин урамы,Совет урамы;
- Иске Завод торак пунктында урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру яки алыштыру;
- Иске Завод торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Югары Ушма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.З.Исмәгыйлев